ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2020 Олы Кайбыч ав. 97

Кайбыч муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәте үткәрә торган пенсия яшен арттыру һәм гражданнарның хезмәт законнарында каралган хезмәт хокукларын һәм ирекләрен яшенә карап чикләүне тыюны тәэмин итү буенча кабул ителгән карарларны үтәү, шулай ук пенсия яшендәге гражданнарның мәшгульлеген саклап калуга һәм үстерүгә юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыру максатларында Россия Хезмәт министрлыгының 2018 елның 17 сентябрендәге 16-0/10/В-7094 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Кайбыч муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2014 елның 22 декабрендәге 620 номерлы карары белән расланган Кайбыч муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«эш бирүчеләр тарафыннан хезмәт хакы түләүнең эш хакының федераль законда билгеләнгән минималь куллану бюджеты зурлыгы кыйммәте күләменнән түбән булмаган һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәрен түләүдән түбәнрәк булмаган күләмдә үз вакытында түләвен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар, шулай ук халыкның, шул исәптән пенсия яшендәге гражданнарның реаль керемнәрен арттыру чаралары әзерләү;»;

3 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«пенсия алды яшендәге затларга карата эш бирүчеләр белән үзара бәйләнешне координацияләү.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда һәм http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Н.Макаров